# «Чык тамчысы»

**МАДОУ**

**Детский сад №49**

**«Росинка»**

## *Май, 2020 ел*

**Газетабызның бу саны #ЭКОВЕСНА2020 кысаларында уза торган санитар-экологик чараларга багышлана**

Поздравляем вас с Днем Победы! Днем, когда наша страна и все, кто боролся с фашизмом по всему миру, одержали такую долгожданную победу! Наши деды и прадеды воевали за счастливое будущее всего свободного мира! И мы должны доказать, что достойны этой победы!

В великий день памяти — день победы хочется поздравить всех и особенно главных виновников торжества — ветеранов. Сказать им спасибо за их подвиги, за жизни, отданные во имя спасения страны. Пожелать вам здоровья, процветания, материального благополучия, долгих лет. Мирного всем неба над головой.



# Табигатьне саклыйк!

Табигать ул узен яклый алмый,
Үч тә ала алмый кешедән.
Ул бары тик рәнҗи генә ала,
Куркыйк шушы рәнҗеш төшүдән.
Фәнис Яруллин.

“Табигать – тиңсез хәзинә!” , "Табигатьне саклагыз!" Бу сүзләрне без бик еш ишетәбез. Әмма, аларның чын мәгънәсен без аңлап бетерәбезме икән? Һәрвакытта да аңлап бетермибез шул. Ә бит бу сүзләргә киләчәгебез турында зур мәгънә салынган. Туган як табигате − чиста һава һәм экологик яктан чиста ашамлыклар гына дигән сүз түгел әле ул. Ул − Туган илебезнең матурлыгы да, жаны да. Туган як табигате ул − калкулыктагы кипкән печән эскертләре арасындагы каен агачлары да, тынлык һәм хуш исләр белән тулган чыршы урманы да, иң кызу җәй көннәрендә дә салкын һәм көмештәй саф сулы күлләр дә, кечкенә генә инештән башлап, зур елгага таба ыргылучы елгачыклар да.

Бүгенге көндә табигать безнең ярдәмгә мохтаҗ. Ул яралы, сагышлы. Елга-күлләре кипкән, чишмәләре дә челтерәми, кошлар да элеккечә сайрамый. Урманнарда ботарлап ташланган агачлар башларын түбән игән. Алар кешенең рәхимсезлегенә уфтаналар кебек. Кешеләр беренче урынга матди яктан яхшы торуны, акчаны, престижлы эш урынын куялар, экология турында уйламыйлар яки уйлаудан туктыйлар. Кырыс тормыш кануннары җир йөзенең киләчәге турында уйларга вакыт калдырмый. Нигә шулкадәр битараф, рәхимсез, шәфкатьсез без табигатькә?

Туган илебезнең чиста сулы елга һәм күлләрен пычрату, очсыз-кырыйсыз урманнарны бер мәгънәсез кисеп бетерү, химия заводларының агулы газлары белән чиста һавабызны бозып бетерү, хәрби уеннар вакытында туфракны һәм һаваны агулау, авиация ягулыгының агулы калдыклары − болар әле хәзерге цивилизациянең туган ягыбыз табигатенә салган зыянының бер өлеше генә. Табигатьне пычратучылар белән көрәшне без бүгеннән үк башламасак, берничә дистә елдан соң, бөтен тереклек көеп беткән чүл уртасында калуыбыз бар бит.

Җирдә тереклек бары һава-атмосфера булганда гына яши ала. Бүгенге көндә промышленность, транспорт үсү нәтиҗәсендә һавада кислород һаман кими бара. Моннан тыш, әле кислородны төп эшләп чыгаручы - урманнарның да мәйданнары көннән-көн кими. Атмосфераның пычрануы кислота яңгырлары, парник эффекты, сөрем томаны, озон тишеге кебек куркыныч нәтиҗәләргә китерә.

Кешеләр! Әйдәгез әле, табигатькә карата бераз мәрхәмәтлерәк булыйк! Аны саклап калу өчен бар көчебезне кызганмыйк! Табигать һәм бөтен галәм киңлеген саклап калу — безнең бурыч кебек фикерне аңлап була бу юллардан.

Табигать – кешенең яшәү урыны. Без табигатьне яратабыз, аннан җаныбызга ямь, күңелебезгә тынычлык алабыз. Табигатьне саклау – ул үзебезне, киләчәгебезне, өебезне саклау дигән сүз. Әйе, без табигать белән тәңгәллектә генә яши алабыз. Һәр гамәлне акыл белән башкарырга кирәк, шул чакта гына без матурлыкны, табигатьне коткарып кала алырбыз.

**“Эко-весна” кысаларында балалар бакчасында төрле акцияләр оештырылды. Бу акцияларда эти-әниләр, балалар, бакчабыз педагоглары бик актив катнаштылар.**

## Акция «Берегите первоцветы»













# Акция “Чистая земля”




















## Ә сез беләсезме?




Газета 49 нчы балалар бакчасының өлкән тәрбиячесе Гиндуллина Гөлнара Хәйрулла кызы тарафыннан чыгарылды.